СОВЕТ АЛБАЙСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д.28, с. Албай,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422176

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЛБАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Үзәк ур., 28 нче йорт, Албай авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422176

тел.(факс): (85563) 3-05-08; e-mail: Alb.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

КАРАР
№ 2-2

РЕШЕНИЕ
от 17.11.2020г.

**Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлеге Советының 2016 нчы елның 29 нчы июлендә кабул ителгән №1-11 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлеге Башкарма комитеты турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясе җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Албай авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлеге Советының 2016 нчы елның 29 нчы июлендә кабул ителгән 1-11 нче карары белән расланган (№ 3-33 05.06.2018 ел, № 3-41 21.03.2019 елгы редакциядә) Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлеге Башкарма комитеты турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 4.11 пунктына түбәндәге абзац өстәргә:

«- полиция участок уполномоченные вазыйфасын биләгән хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына хезмәткәр тарафыннан күрсәтелгән вазыйфаны биләү чорында торак урыны бирә».

2. Әлеге карарның 1.1 пункты 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы http://mamadysh.tatarstan.ru/ рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo. tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлеге башлыгы И.П. Крешковка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Албай авыл җирлеге башлыгы,
Совет председателе И.П. Крешков